МИНИСТЕРСТВО СТРОИТЕЛЬСТВА, АРХИТЕКТУРЫ И ЖИЛИЩНО-КОММУНАЛЬНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТӨЗЕЛЕШ, АРХИТЕКТУРА ҺӘМ ТОРАК-КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

№ ____382/о______

П Р И К А З Б О Е Р Ы К

«__18___»_____09_________2024

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының аерым боерыкларын гамәлдән чыккан дип тану турында

«Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт үткәрүне оештыру турында» 2013 елның 25 июнендәге 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертелүгә бәйле рәвештә

Боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының түбәндәге боерыклары гамәлдән чыккан дип танырга:

«Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларның техник торышына мониторинг уздыру тәртибен раслау турында» 2022 елның 25 октябрендәге 139/о номерлы;

«Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларның техник торышына мониторинг үткәрү тәртибен раслау турында» 2022 елның 25 октябрендәге 139/о номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 9 июнендәге 96 номерлы.

2. Юридик бүлеккә (Р.И. Кузьминга) дәүләт теркәвенә алу өчен әлеге боерыкның Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрелүен тәэмин итәргә.

3. Массакүләм мәгълүмат чаралары белән үзара хезмәттәшлек секторына (Р.Җ.Зәйнуллина) әлеге боерыкның
«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының рәсми сайтында урнаштырылуын тәэмин итәргә.

4. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары М.Х.Салиховка йөкләргә.

Министр М.М.Айзатуллин

Отдел контроля исполнения документов